# КАРАР

**2025 елның 27 ноябре** **№ 1**

**Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Кукмара муниципаль районының Мәнзарас авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы белән 2025 елның 24 һәм 25 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәт итүгә контракт имзалаган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларынан кала,1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, тоту;
- урамны яктырту
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү
- ремонт, коймалар урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су басу манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булып саналмыйлар) урнаштыру, ремонтлау һәм аларга күрше территорияне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 297 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 161.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 159 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 2 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Өлге авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Манзарас авыл җирлегенең Өлге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 1 төркем инвалидларыннан; 18 яшькә кадәрге 3 һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрдән һәм ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә ашыгыч хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаиләләре әгъзаларыннан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә хезмәт итүгә контракт имзалаган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларынан кала,1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын урнаштыру, ремонтлау, тоту;
- урамны яктырту
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү
- ремонт, коймалар урнаштыру, традицион күмү урыннарын төзекләндерү;
- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су басу манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, ташуны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау
- беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү
- һәйкәлләрне (Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булып саналмыйлар) урнаштыру, ремонтлау һәм аларга күрше территорияне төзекләндерү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

- кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыеннын нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы урынбасары — Ф.З.Махмутов